КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 15 декабрь г.Казань № 1619

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 9 март, 224 нче карары белән расланган 2023 елда мәҗбүри эшләргә хөкем ителгән затларны эшкә урнаштыру максатларында Татарстан Республикасында карап тоту өчен төзәтү үзәкләре участокларын төзү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елда мәҗбүри эшләргә хөкем ителгән затларны эшкә урнаштыру максатларында Татарстан Республикасында карап тоту өчен төзәтү үзәкләре участокларын төзү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2023 ел, 9 март, 224 нче карары белән расланган 2023 елда мәҗбүри эшләргә хөкем ителгән затларны эшкә урнаштыру максатларында Татарстан Республикасында карап тоту өчен төзәтү үзәкләре участокларын төзү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктның унбишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«проект һәм (яки) тикшеренү эшләрен башкаруга, модульле корылмалар төзүнең смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген тикшерү өлешендә проект документациясенә дәүләт экспертизасын уздыруга (әгәр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә модульле корылмалар төзүнең смета кыйммәте дөрес булуы проект документациясенә дәүләт экспертизасын уздыру барышында тикшерелергә тиеш булса), әзер модульле корылмалар, комплектлау частьләре,

җиһазлар һәм модульле корылмаларны монтажлау, җыю, урнаштыру һәм файдалануга тапшыру өчен кирәкле башка товарлар сатып алуга, шулай ук корылмаларны субсидия алучының территориясендә урнаштырыла торган урынга алып барып куюга шартнамәләр күчермәләрен – әгәр төзәтү үзәге участогы модульле корылмалар кору юлы белән төзелгән булса;»;

13 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«проект һәм (яки) тикшеренү эшләре, модульле корылмалар төзүнең смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген тикшерү өлешендә проект документациясенә дәүләт экспертизасы (әгәр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә модульле корылмалар төзүнең смета кыйммәте дөрес булуы проект документациясенә дәүләт экспертизасын уздыру барышында тикшерелергә тиеш булса) – әгәр төзәтү үзәге участогы модульле корылмалар кору юлы белән төзелгән булса.»;

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Бирелә торган субсидия күләме (С) сумда түбәндәге формула буенча билгеләнә:

әгәр төзәтү үзәге участогы капиталь төзелеш объекты базасында төзелгән булса:

$$С = (P_1 + P_2 + P_3 + ... + P_n) \times 0,5;$$

әгәр төзәтү үзәге участогы модульле корылмалар кору юлы белән төзелгән булса:

$$С = (P_1 + P_2 + P_3 + ... + P_n) \times 0,5 + P_p \times 0,999,$$

монда $P_1$, $P_2$, $P_3$, $P_n$ – әлеге Тәртипнең 7 пунктындагы унберенче – унсигезенче абзацлары нигезендә субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә әлеге Тәртипнең 13 пунктында күрсәтелгән товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр төрләре буенча субсидия алучының өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча фактта тотылган чыгымнары;

$P_p$ – проект һәм (яки) тикшеренү эшләре һәм модульле корылмалар төзүнең смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген тикшерү өлешендә проект документациясенә дәүләт экспертизасы (әгәр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә модульле корылмалар төзүнең смета кыйммәте дөрес булуы проект документациясенә дәүләт экспертизасын уздыру барышында тикшерелергә тиеш булса) буенча өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча фактта тотылган чыгымнар.

Мәҗбүри эшләргә хөкем ителгән затларны эшкә урнаштыру максатларында карап тоту өчен бер урынга исәпләнгәндә субсидия күләме модульле корылмалар кору юлы белән төзәтү үзәге участогын оештырганда 483 мең сумнан һәм капиталь төзелеш объекты базасында төзәтү үзәге участогын оештырганда 252 мең сумнан артып китә алмый.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин